РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ Буа шәһәре КАРАР

27 июль 2021 ел № 1-15

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Буа муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясы, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Татар Буасы авыл җирлеге, Ырынгы авыл җирлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча белдерелгән җирлекләр халкының ризалыгын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын һәм аңа материалларны закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Буа муниципаль районы Советы вәкиле итеп Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдиновны билгеләргә.

3. Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 03 августындагы 3-55 номерлы «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү буенча Буа муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай

ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны Буа муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (рәисе А.М. Сибгатуллин) йөкләргә.

Буа муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов